


ЭКОСӘХИФӘ

# ХИКМӘТЛЕ КОШ

**КАЗАННЫҢ СОВЕТ РАЙОНЫНДА УРНАШКАН ЭКОЛОГИЯ ЮНӘЛЕШЕНДӘ ЭШЛӘҮЧЕ 79 НЧЫ ЛИЦЕЙНЫҢ ЯШЬ НАТУРАЛИСТЛАРЫ БҮГЕН ГОРКИ-ӘМӘТ УРМАНЫНДА КҮЧМӘ КОШЛАРНЫ КҮЗӘТӘ.**

## Белә идеңме?



1 нче апрель – Халыкара кошлар көне. Ул 1906 нчы елдан билгеләп үтелә. Шул елның 1 нче апрелендә Халыкара кошларны саклау конвенциясенә имза куела. Бу конвенциягә Россия 1927 нче елда кушыла.

## Фәнни мәгълүмат

Горки-Әмәт урманын үз итүче күчмә кошларның берсе – Шөпшәашар. Ул – карчыгалар гаиләсеннән. Ерткыч кош. Яхшы күрә, корбанын тотып алу өчен, зур тырнаклары һәм көчле томшыгы бар. Татарстанның Кызыл китабына кертелгән. Шөпшәашар туган якларга башка кошларга караганда соңрак кайта. Шөпшәләр белән туклангангa, шундый хикмәтле исем алган. Моннан тыш, әлеге ерткыч кош бакалар, кәлтә, кимерүчеләр белән дә туклана.

## Бүләкле булыйм, дисәң...

Дустым, язгы табигатьне күзәтәсеңме?
Әйдә, тиз генә җыен да, беренче булып,
язгы урман яки күчмә кошлар сурәтләнгән
фотоңны sabantui@bk.ru адресына юлла һәм
79 нчы лицейдан кәттә бүләк от!

*Фото Горки-Әмәт урманында урнашкан «Дом» экоүзәге фәнни хезмәткәрләренең шәхси архивыннан алынды.*